УДК 782:821.512.145-2

*Э.М. Галимова*

# К. ТИНЧУРИННЫҢ ДРАМА ӘСӘРЛӘРЕ ҮСЕШЕНӘ МУЗЫКАНЫҢ ЙОГЫНТЫСЫ: «Каракүз» музыкаль кыйссасы мисалында

Статья раскрывает эстетическую специфику музыкальных драм Карима Тинчурина, в которых главную роль играют музыка и сценическое действие. В татарской музыкальной культуре первый успешный пример соединения музыки и литературного наследия Карима Тинчурина мы видим в творчестве Салиха Сайдашева, который в течение короткого периода создал новую эстетическую систему в искусстве. В данной статье определяются важные тенденции современной режиссуры спектаклей в жанре музыкальной драмы, а также раскрываются практические вопросы, касающиеся создания музыкальной фабулы. На примере музыкальной легенды «Каракуз» в постановке Мензелинского государственного татарского драматического театра им. С. Амутбаева попытаемся определить роль музыки и аспекты её влияния на развитие драматического действия.

**Ключевые слова:** Карим Тинчурин, музыкальная драма, Салих Сайдашев, музыкальная легенда «Каракуз».

Кәрим Тинчурин – татар драматургиясен яңа биекләргә күтәргән олуг әдипләребезнең берсе. Аның иҗаты белән милли драматургиядә саллы бер дәвер башлана. Билгеле ки, аның драматургия, сәхнә сәнгате өлкәсендәге тәүге иҗат тәҗрибәләре XX гасырның унынчы елларыннан ясала башлый. Алга таба әлеге өлкәләрнең мәшһүр шәхесе булып танылу вакыты 1920–1930 елларга туры килә. Ул милли драматургия һәм татар театры сәнгате үсешендә Г. Камал, Г. Кариевлар мәктәбе традицияләренә таянып, шуларны алга таба уңышлы иҗади яктан үстереп алып киткән, шул нигездә үзе дә гаҗәп оригиналь, үзенчәлекле, кабатланмас иҗат әһеле булып танылуы белән билгеле.

Кәрим Тинчурин иҗатын, күпкырлы эшчәнлеген 1920–1930 еллар татар әдәби, мәдәни хәрәкәтеннән аерып карап булмый. Бу елларда әдәбият һәм сәнгать белемендә, театр тәнкыйтендә аның иҗатына мөнәсәбәт алгы планга чыга. Нәтиҗәдә драматургия, театр мәсьәләләре белән бәйләнештә аңа бәя бирү игътибар үзәгендә була. 1934 елда Мәскәүдә Совет язучыларының Беренче бөтенсоюз съездында Кави Нәҗми татар әдәбияты турында доклад белән чыгыш ясый. Чыгыш нигезендә ул Кәрим Тинчурин иҗатының сәнгатьчә оригинальлеген һәм үзенчәлеген билгеләп: «Аның иҗатында зур урынны фольклор – халык җырлары, уеннар, биюләр һәм музыка ала. Тамашачыга ул аны мастерларча күрсәтеп бирә белә», ди. Бу чорда тәнкыйтьчеләр, шул исәптән К. Нәҗми дә, К. Тинчуринның революция сәясәте, социалистик чынбарлык темасына язмавын аның кимчелеге итеп күрсәтәләр,

«иҗатында революция бурычларын аңлауда өстән йөзү» хакында сүз алып баралар. Шулай ук байларны һәм дин әһелләрен тискәре яктан ача белмәүдә гаеплиләр. К. Нәҗми һәм башка тәнкыйтьчеләр татар буржуазиясе һәм интелегенциясенең йөзен бик дөрес күрсәтүче иң уңышлы әсәре итеп, К. Тинчуринның «Җилкәнсезләр» пъесасын санийлар.

Игътибар итсәк, мелодрама жанры – татар тамашачысы өчен драматургиянең иң сәнгатьчән, сәхнә өчен нык яраклашкан төрләреннән, дип әйтергә кирәк. Мелодрамада сәнгати чаралар, театраль эффектлар тамашачыны тәэсирләндерү өчен махсус кулланылалар. Аның әһәмиятле үзенчәлеге – драма, җыр сәнгате, пантомима, балет һәм сынлы сәнгатьнең һәр төре аерымлыкларын бергә уңышлы тоташтырылуда. Декорация байлыгы һәм аның еш алмашынуы, яктылык эффектларының күп кулланылуы да мелодраманың иң сәнгатьчән төр булуына ишарә. Мелодрамада сөйләмнән тыш (экстралингвистик) чаралар: яктылык, тавыш, музыкаль бизәлеш, пантомима, бию – жанр өчен бик әһәмиятле драматизмны үстереп, көчәйтеп җибәрү өчен кулланыла. Әлбәттә, бу очракта үрнәк буларак без К. Тинчуринның «Зәңгәр шәл» мелодрамасын атый алабыз.

Бүген исә, сезнең игътибарыгызны Кәрим Тинчуриның «Каракүз» мелодрамасына юнәлтәсем килә. Әлеге яңа әсәр яшь режиссёр Рамиль Фазлыев тарафыннан зур үзгәрешләр кичерде һәм, нәтиҗәдә, «музыкаль кыйсса» буларак дөнья күрде. Ни өчен дигәндә, режиссёр фикерен аңлатып үтәсе килә. Әкият яки риваять булсын, мелодрама жанрындагы зур күләмле драматик әсәр булсын, аларда хыялый, һәр яктан камил җәмгыять корырга омтыла торган рухият үзенчәлеге чагылыш таба. Шулай ук фабула ягыннан карасак та, аның төзелешенең ахыры ни белән бетәсе билгеле була һәм сәбәп-нәтиҗә бәйләнешләре ачык күренеп тора. Капма-каршы күренешләрнең киеренкелек тудыру өчен кулланылуы, уңай каһарманның аңа каршы булган явыз каһарман тарафыннан эзәрлекләнүе, кортлыкның, явызлык-үчлекнең кабатлануы күзәтелә.

Минзәлә татар дәүләт драма театры әлеге әсәрне сәхнәләштерергә уйлагач, әлбәттә, эчтәлекне ачып бирә торган лирик җырлар, такмаклар, төп геройлар башкаруындагы дуэтларга игътибарны юнәлтергә мәҗбүр була. Автор үзе ук әлеге әсәрнең куелышында музыка төп рольне алып торачагын көн кебек ачык белгән диган фикер туа.

Композитор буларак, Минзәлә татар дәүләт драма театры миңа музыка язырга тәкъдим ясагач, һичшиксез, бу әсәргә зур кызыксынуым барлыкка килде. Әлбәттә, музыка язарга керешкәнче, әлеге жанр кысаларында автор тарафыннан әйтелгән фикерне ачыкларга кирәк. Композитор буларак, музыка теле ярдәме белән син аны дөрес итеп җиткерә белергә тиеш. Гомумән, музыка, ысулларга бай булганга күрә, актёрларга илһамланып уйнарга һәм төрле яктан образны ачарга мөмкинчелек бирә. Нәтиҗәдә, әсәр кысаларында һәр-

бер образга музыкаль характеристика бирү, әлеге фикернең бер дәлиле булып тора. К. Тинчурин композицион фабула кысаларында кайда нинди җыр яки бию булачагын алдан ук күзаллап төзегән. Мелодекламация кулланган урыннары да шактый. Димәк, автор опера яки оперетта либреттосын күздә тотып язган. Билгеле ки, драма артистлары опера кануннарына туры китереп ария, ариозоларны башкарып чыгар өчен зур әзерлек кирәк һәм күп кенә театрларда бу бик сирәк күренеш. Шуңа күрә, музыкаль яктан җыр жанрларын гадиләштерү, әмма бию, мелодекламация урыннарын саклап калу – әсәрне сәхнәләштергән вакытта төп бурычларның берсе булып калды. Нәтиҗәдә, тылсымга ия булган драматик эпизодларның әһәмияте, образларның күп булуы һәм әсәрнең эзлекле эчтәлеге «кыйсса» жанрына бик якын булуын исбатлады.

Әсәрне Минзәлә татар дәүләт драма театры үзенең 80 еллык юбилей уңаеннан яңа премьера буларак тамашачы хозурына 2016 елның 17 ноябрендә зур уңыш белән тәкъдим итте. Нигездә, К. Тинчуринның әлеге әсәре бик озын һәм, гомумән алганда, дүрт сәгатьлек тамаша булырга тиеш икәнлеге ачыкланды. Аны кыскарту һәм тамашачыга эчтәлеген ачу, шулай ук авторның фикерен җиткерү нияте белән режиссёр, яңа образ буларак, ике дәрвиш рольләрен кертә. Чөнки бүгенге көн режиссура башка вакыт кысаларында чагыла. Тамашачы драматургия һәм режиссура ягыннан кертелгән кирәкмәгән тынлык билгеләрен бик тиз сизә. Шул нисбәттән, күп режиссёрлар кыскалык та осталык дигән гыйбәрәдән чыгып эш итәләр.

«Каракүз» музыкаль кыйсса әсәре өчен 28 музыкаль номер иҗат ителде. Кыйссаның төп лейтмотивы итеп – дәрвишләр темасын атар идем. Әлеге тема тамашачыга әсәрнең рухын тоярга һәм алга таба буласы вакыйгаларны сиземләү өчен ярдәм итә.

Әсәрнең эчтәлегенә туктталсак, вакыйга Шәрыкның бер шәһәрендә бара. Хәерче кыз Каракүз зур мәйданнарда һәм сәүдә базарларында җырлап, биеп көн күрә. Җырларында ул халыкның авыр тормышы, замананың чынбарлыгы, дөреслекнең юлын һәм чарасын күрү хакында җырлый.

Тинчурин шулай ук сатира рәвешендә Җанбәк ханның өч хатын белән бимазаланып яшәве, аңа кечкенә генә булса да бәхет хисе бирүче бытбылдыклар ярышлары үткәрүе, Җанбәк ханның сараенда яшь чуриләрнең кол булып яшәүләре, халыкның баш калкытмавы һәм бүген дә сәүдәгәрләр өчен актуаль булган зур салым булуы хакында – көнкүреш проблемаларның берсе турында яза. Җанбәк ханның зур сараен һәм үзенең эчке халәтен тасвирлый торган төп лейттеманы карап узыйк.

Әсәрнең эчтәлеген алга таба дәвам итсәк, Каракүзне очраклы рәвештә күргән Җанбәк хан аңа гашыйк була. Ханнан котылу чарасы итеп, Каракүз аңа әйләнмәле бакча ясарга куша. Шул ук вакытта Каракүз сөйгәне Иделбай белән ханны алдарга юл эзлиләр. Туй буласы көнне Идел-

бай утларны аерырга тиеш була. Халык арасында гауга килеп чыккач, егет кызны күтәреп кача.

Гомумән, тәнкыйтьчеләр тарафыннан К. Тинчуринның драматургиясенә карата әйтелгән фикерләр әлеге әсәрдә ярылып ята. Ә менә Кәрим Тинчуринның драма әсәрләре үсешенә музыканың йогынтысы нинди соң? Һичшиксез, музыка ысуллары бик көчле әһәмияткә ия. Чөнки музыкаль драма жанрын күздә тотсак, драматургия үзенчәлекләре нәкъ менә музыканың сихри көче һәм аһәне аша ачыла дигән нәтиҗәгә килә алабыз.

Каракүз образы 4 лейттема аша ачыла. Беренче лейттеманы без карап үттек инде. «Ардаклы бала» дип исемләнгән икенче лейтмотив Каракүзнең ятимлеге хакында һәм шул вакытта халыкның чиксез авыр тормышын сурәтли. Ләкин Каракүз барыбер күңелен төшерми, җырын шәрык биюе белән дәвам итә һәм нык рухлы кыз икәнен әсәр барышында исбатлый. Өченче лейтмотив Каракүзнең Иделбайга мәхәббәтен чагылдыра торган тема. Музыка ысуллары ярдәмендә ул тылсымга ия булырга тиеш, дип аңлатты режиссёр. Канон һәм полифония серләре ярдәмендә сихри тема «Зынла-зынла» җыры язылды. Дүртенче лейттема Каракүз Җанбәк белән кискен сөйләшүен тәмамлагач мелодекламация буларак яңгырый. Каракүз туры сүзле булуы белән Җанбәкне шаккатыра һәм ачуын чыгара.

Әлбәттә, спектакльнең икенче бүлеге ахырында яңгырый торган Иделбай белән Каракүз башкаруындагы мәхәббәт дуэты – әсәрнең иң төп лирик эпизодларының берсе. Гомумән, спектакльда биюләр, күмәк эпизодлар һәм фон буларак яңгыраган лейттемалар бихисап. Чөнки һәрбер образ һәм эпизод музыка аһәңе аша тамашачы алдында ачыла. Иң уңышлы күмәк эпизодлардан «Чуриләр биюен», «Сәүдәгәрләр биюен» һәм, әлбәттә, Каракүз үзенең образын шәрык биюе аша исбатлавын, әйтеп үтәргә кирәк.

Нәтиҗәдә, К.Тинчурин драма әсәрләрен барлагач һәм шул ук вакытта мәгънәви мотивларын, конфликт, фабула алымнарын, эчтәлек структурасын һәм сәнгатьчәлеген тикшереп карагач, аларның нигезенә театраль яктан көчле тәэсирлелек салынганын аңлыйсын. Минем өчен «Каракүз» әсәренең музыкаль бизәлеше өстендә эшләү зур тәҗрибә булды. Һичшиксез, бөек әдибебез К. Тинчурин драматургиясе бүгенге көндә дә эчтәлеге белән шулкадәр актуаль икәнлеген, әлеге әсәр тагын бер кат исбатлады.

***Галимова Эльмира Мөнир кызы,***
*сәнгать фәннәре кандидаты, Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының театр һәм музыка бүлеге мөдире*